ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КӘРКӘҮЧ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
НИГЕЗЛӘМӘСЕ

26 апрель 2021 ел №5

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының
"Кәркәүч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге
территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү турында

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы, «янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим билгеләү турында»23.04.2001 елдагы 280 номерлы Карарын үтәү йөзеннән, язгы-җәйге чорда янгын куркынычы дәрәҗәсе артуга бәйле рәвештә, "янгын куркынычсызлыгы турында" 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы, "янгын куркынычсызлыгы турында" 1993 елның 18 маендагы 1866-XII карар бирәм:

1. 2021 елның 26 апреленнән 16 маена кадәр Кукмара муниципаль районының «Кәркәүч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә янгынга каршы махсус режим урнаштыру.

1.1. Янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда корыган үләнне һәм чүп-чарны яндыруны; ачык утта (учак, мангалы) ризык әзерләүне, торак пунктлар территориясендә, шулай ук урман-парк зоналарында, урман массивлары белән чиктәш торф участокларында һәм ачык территорияләрдә 1-3 класслы пиротехник эшләнмәләрне куллануны тыярга кирәк.

1.2. Авыл җирлеге территориясендә урнашкан учреждение һәм предприятие җитәкчеләренә язгы-җәйге янгын куркынычы чорында халык,хезмәткәрләр һәм укучылар арасында янгын куркынычсызлыгы чараларын пропагандалау һәм агитацияләү буенча эш алып барырга, ведомство карамагындагы объектларда территорияне коры үләннән һәм чүп-чардан арындыру буенча чаралар күрергә; баланста булган тышкы янгын су белән тәэмин итү чыганакларының эшчәнлеген тикшерергә; янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда янгын куркынычсызлыгы эшләрен чикләргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

Кәркәүч авыл җирлеге бышлыгы М.Ф.Зәйнетдинов